**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «01» апреленнән № 88

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып һәм инвалидлар өчен мөмкинлекләр тәэмин итү максатларында инвалидларның торак биналарын һәм инвалид яшәгән күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне тикшерү буенча комиссия төзү, бу комиссияне төзү һәм комиссиянең эш тәртибен раслау турында» 2016 елның 26 декабрендәге 526 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына инвалидлык турында белешмәләр бирү өлешендә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 10 февралендәге 114 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып һәм инвалидлар өчен мөмкинлекләр тәэмин итү максатларында инвалидларның торак биналарын һәм инвалид яшәгән күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне тикшерү буенча комиссия төзү, бу комиссияне төзү һәм комиссиянең эш тәртибен раслау турында» 2016 елның 26 декабрендәге 526 номерлы карарына 2 нче кушымтада 3 бүлекнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасында «инвалид дип танылган» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«Вәкаләтле федераль орган (вәкаләтле орган) ведомствоара электрон хезмәттәшлек тәртибендә Россия Федерациясе Пенсия фондыннан инвалидлык билгеләү фактын раслый торган белешмәләрне соратып ала. Ведомствоара гарызнамә ведомствоара электрон бәйләнешнең бердәм системасын һәм аңа

тоташтырыла торган ведомствоара электрон бәйләнеш региональ системаларын кулланып электрон документ формасында күрсәтелгән вәкаләтле органнар тарафыннан җибәрелә. Күрсәтелгән белешмәләр Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан гарызнамә алган көннән алып 3 эш көне эчендә бирелә. Инвалид дип танылган граждан (инвалид баласы булган гаилә) үз инициативасы белән күрсәтелгән вәкаләтле органнарга инвалидлык билгеләү фактын раслаучы белешмәләр, гражданны (баланы) инвалид дип тану турындагы документлар, шул исәптән инвалид дип танылган гражданның (баланың) медик-социаль экспертиза актыннан өземтә тапшырырга хокуклы;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (инфраструктур үсеш буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов